ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2022 с.Старое Дрожжаное №291

2022 елның II һәм III кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2022 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2022 елның 29 мартындагы 215/пр номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Авыл җирендә яшәүче яшь гаиләләрне һәм яшь белгечләрнең яшәү шартларын яхшырту максатларында «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2014-2020 елларга федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 2022 елның II һәм III кварталларына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 29 000 сум 00 тиен күләмендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге начальнигы Р.Р. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов